РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Г.Тукая ул., д. 7, с. Шадки, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Г.Тукай ур., 7 нче йорт, Шәтке авылы, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94319624 ОГРН 1061675011914 ИНН/КПП 1619004482/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 23** **« 15 » ноябрь 2021 ел.**

**Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 10.12. 2015 ел № 12 нче "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 10.12.2015 ел № 12 "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" карарына ( 06.05.2020 ел № 10, 28.10.2020 ел № 20, 01.02.2021 ел № 1 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1-4 кушымтаның 3 бүлеге исемен түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да бар.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шәтке авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Г.Кадыйров